# Шигъри сандык

№ 4 Апрель 2023 ел



БЕР ТӨРЛЕ ТҮГЕЛ ТОРМЫШ

Көзен агач яфрак кояя,
Хәлсезлеккә бирешкәндәй,
Хәтта кешеләр дә тоя
Куңел кылын озелгэндэй.

Авырлыклар төшкән кебек.
Кыен-дибез-сулыш алу.
Каты итеп типкән кебек
Йөрәк, сизеп ару-талу.

Тик көзләр утә бит ул,
Агач яңадан чәчәк ата,
Тормыш шундый төрле бит ул
Кыштан сон яз кире кайта.

Бертөрле булса тормыш,
Ямен белмәс идек аның,
Барса да йөрәктә сугыш,
Язын бөре бирер талын.

*РАЯН ШАКИРОВ*